**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 4 июнендәге 1662 номерлы карары**

**Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен Казан шәһәренең торак фондындагы торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен үзгәртү буенча чик индексны билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясының 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын раслау тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында»гы боерыгының 4.1 пунктына таянып, **карар бирәм**:

1. Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен Казан шәһәренең торак фондындагы торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен үзгәртү буенча чик индексны 2025 елның 1 июленнән 2026 елның 30 июненә кадәр 11,36% күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар А.Р.Нигъмәтҗанов**